| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2025 Кошман ав. № 3

Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5.1. пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «Биометрик персональ белешмәләрдән файдаланып финанс затларын идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган Россия Федерациясе гражданы паспорты йә шәхесне таныклаучы башка документны Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарда, мәгълүмат технологияләреннән файдаланып күпфункцияле үзәкләрдә идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән (бердәм, республика порталы чарасы белән мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);»;

- 2.10. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы вәкаләтле экспертлар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.»;

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб –адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Л.Р. Сафина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Кушманского сельского поселения
ИНН 1621003133